Нияз Акмал истәлегенә: Чаллының Үзәк китапханәсендә Н. Акмалны искә алу кичәсе үткәрелә // Шәһри Чаллы. – 2024. - № 14 (28 февраль). – Б. 3.

# Нияз Акмал истәлегенә

**Якты йөзле, эчкерсез, талантлы шагыйрь, прозаик, журналист Нияз Акмалга, исән булса, быел 14 февральдә 70 яшь тулган булыр иде.** Ул 53 яшендә кинәт йөрәге туктап китеп барды. Сарман районы Каташ-Каран авылы егете туган авылы зиратында җирләнде.

Чаллының Үзәк китапханәсе (ГЭС 4/14А) 29 февральдә 13 сәгатьтә Нияз Акмалны искә алу кичәсе үткәрә. Кичәгә аны хөрмәтләп туган ягыннан «Сарман таңнары» әдәби-иҗат берләшмәсе вәкилләре һәм Казаннан шагыйрә Илсөя Ихсанова, күренекле шагыйрь Газинур Морат, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, шагыйрь һәм прозаик Рафис Корбан, композиторлар Риф Гатауллин һәм Айдар Тимербаев, Татарстанның халык артисткасы Фәридә Сафина, җырчы Гөлдания Хәйруллина, җырчы һәм журналист Зөлфәт Зиннуров, радиожурналист Нәсим Акмал, Уфадан шагыйрьнең сабакташы шагыйрә Фәния Габидуллина килә.

Ниязның Чаллыдагы якташларын, университеттагы сабакташларын, шигырь сөюче һәркемне искә алу кичәсенә чакыралар.